| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 6 июне Олы Ачасыр авылы № 16

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 23 апрелендәге 10/2 номерлы карары белән расланган (2019 елның 12 августындагы 19 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 16 номерлы, 2021 елның 12 мартындагы 10 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты бухгалтер хезмәтләре хезмәткәрләренең (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына кертелгән вазифалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Бухгалтер хезмәте хезмәткәрләренең хезмәт хакын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 23 апрелендәге 10/2 номерлы карары белән расланган (2019 елның 12 августындагы 19 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 16 номерлы, 2021 елның 12 мартындагы 10 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты бухгалтер хезмәтләре хезмәткәрләренең (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына кертелгән вазифалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазифа хезмәт хакы түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Муниципаль берәмлектә халык саны | Вазыйфа исеме, хезмәт хакы(сум) | |
|---|---|---|
| | Баш бухгалтер | бухгалтер |
| 3,5 меңгә кадәр кеше | 23700 | |
| 3,5 меңнән артык кеше | 25 000 | |
| 1,9 меңнән артык кеше | | 22 500». |

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

Олы Ачасыр авыл
жирлеге башлыгы И.М. Саттаров